| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НАДЕЖДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>НАДЕЖДИНО АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

14.07.2022г Надеждино ав. № 34

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегендә Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Советының 2021 елның 27 декабрендәге 19 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегендә инициативалы проектларны гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегендә Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Советының 2021 елның 27 декабрендәге 19 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегендә инициативалы проектларны гамәлгә ашыру тәртибенә кушымтада каралган редакциядә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (халыкка таратырга).
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Кайбыч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге Башлыгы Е.В.Савельева

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Советының 2022 елның 14.07. 34номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегендә инициативалы проектларны гамәлгә ашыру тәртибенә кушымта

## Инициативалы проектны бәяләү критерийлары

| Критерий номеры | Критерий /критерийлар төркеме исеме | Критерий буенча баллар |
|---|---|---|
| 1. | Конкурс сайлап алуын узу критерийлары (ПКОк) | |
| 1.1. | Инициативалы проектны тормышка ашыру:<br> - хосусый коммерция эшчәнлеге (шәхси предприятиеләр, барлар, рестораннар һ. б.);<br>- дини оешмалар (чиркәүләр, мәчетләр һ. б.);<br>- аерым этник төркемнәр мәнфәгатенә хезмәт итүчеләргәе чаралар үткәрүне, объектларны төзекләндерүне, ремонтлауны, төзекләндерүне, хезмәткәрләрне тәэмин итүне күздә тота. | |
| | әйе | 0 |
| | юк | 1 |
| 1.2. | Җирлекнең бюджет чаралары суммасы 300 мең сумнан артып китә | |
| | әйе | 0 |
| | юк | 1 |
| «Конкурс сайлап алуны узу критерийлары» нәтиҗәсе: | «Конкурс сайлап алуны узу критерийлары» төркеменә керүче һәр критерий, проект буенча буенча баллар бирү: | |
| 2. | Рейтинг критерийлары, (Рк) | |
| 2.1. | Инициативалы проектны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге: | |
| 2.1.1. | Инициативалы проектны тормышка ашыруның иҗтимагый файдасы | |
| | проект җирлек халык өчен югары социаль, мәдәни, ял итү һәм башка иҗтимагый файдалы проект буларак бәяләнә:<br>Актив гражданлык позициясе, сәламәт яшәү рәвеше формалаштыруга ярдәм итә, әхлак, толерантлык, башка социаль әһәмиятле сыйфатлар (чаралар, акцияләр, форумнар) тәрбияләүгә юнәлдерелгән;<br>социаль өлкәнең муниципаль объектларын булдыруга, үстерүгә һәм ремонтлауга юнәлдерелгән;<br>иҗтимагый инфраструктура объектларын, төзекләндерү, рекреацион зоналарны, социаль җәлеп итү нокталарын, халык күпләп ял итә торган урыннарны, мәдәни мирас объектларын төзүгә, үстерүгә һәм ремонтлауга юнәлдерелгән;<br>җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзүгә (реконструкцияләүгә), капиталь ремонтлауга һәм ремонтлауга юнәлдерелгән | 5 |
| | проект җәмгыятькә файдасы булмаган буларак бәяләнә | 0 |

| | | |
|---|---|---|
| 2.1.2. | проблеманың актуальлеге (кискенлеге): | |
| | бик югары - проблема халык тарафыннан критик дип бәяләнә, проблеманы хәл итү халыкның тормыш-көнкүрешен тәэмин итү шартларына ярдәм итү һәм саклап калу өчен кирәк | 8 |
| | югары - проблема халык тарафыннан кирәкле дип бәяләнә, аның чишелешенең булмавы тормыш сыйфатына тискәре йогынты ясаячак | 7 |
| | уртача - проблема халык тарафыннан актуаль дип бәяләнә, аны хәл итү тормыш сыйфатын яхшыртуга китерергә мөмкин | 6 |
| | түбән-халык тарафыннан актуаль буларак бәяләнми, аның чишелеше тормыш сыйфатын яхшыртуга китерми | 0 |
| 2.1.3. | Инициативалы проект нәтиҗәләрен карап тору (аңа ярдәм итү) максатларында киләсе чорларда өстәмә бюджет чыгымнарын гамәлгә ашыру зарурилыгы | |
| | юк | 5 |
| | әйе | 0 |
| 2.1.4. | Инициативалы проектны гамәлгә ашыру вакыты | |
| | 1 календарь елга кадәр | 4 |
| | 2 календарь елга кадәр | 3 |
| | 3 календарь елга кадәр | 2 |
| | 3 елдан артык | 1 |
| 2.1.5. | Инициативалы проектны нәтиҗәсенең «тормышка яраклылык вакыты» | |
| | 5 елдан башлап | 4 |
| | 3елдан 5кә кадәр | 3 |
| | 1елдан 3кә кадәр | 2 |
| | 1 елга кадәр | 1 |
| 2.2. | Инициатив проектның оригинальлеге, инновациясе | |
| 2.2.1. | Инициативалы проект идеясенең оригинальлеге, үзенчәлекле булуы | |
| | әйе | 5 |
| | юк | 0 |
| 2.2.2. | Инновацион технологияләр, яңа техник карарлар куллану | |
| | әйе | 5 |
| | юк | 0 |
| 2.3. | Инициативалы проектны конкурс нигезендә сайлап алуда катнашу өчен документлар әзерләү сыйфаты | |
| | әйе | 5 |
| | юк | 0 |
| 2.3.1. | Проект -смета (смета) документлары заявкасына кушымталар булу (төзелеш (реконструкция), капиталь ремонт, ремонт буенча) | |
| | Әйе яки проект-смета (смета) документларына ихтыяҗ юк | 10 |
| | юк | 0 |
| 2.3.2. | Гаризага теркәлгән презентация материаллары булу | |
| | әйе | 10 |
| | юк | 0 |
| 2.4. | Инициативалы проектны әзерләүдә һәм гамәлгә ашыруда җәмәгатьчелекнең катнашуы | |
| 2.4.1. | Гражданнарның инициативалы проектын финанслашу дәрәҗәсе | |
| | инициативалы проект бәясенең 20% нан | 5 |
| | инициативалы проект бәясенең 15% нан 20% ка кадәр | 4 |
| | инициативалы проект бәясенең 10% нан 15% ка кадәр | 3 |
| | инициативалы проект бәясенең 5% нан 10% ка кадәр | 2 |
| | инициативалы проект бәясенең 5% ына кадәр | 1 |
| 2.4.2. | Юридик затлар, шул исәптән социаль юнәлешле коммерциячел булмаган | |

| | | |
|---|---|---|
| | оешмалар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан инициативалы проектны финанслашу дәрәҗәсе | |
| | инициативалы проект бәясенең 20% ын яисә социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан инициативалы проект бәясенең 5% ын финанслашуы | 5 |
| | инициативалы проект бәясенең 15% тан 20% ка кадәр | 4 |
| | инициативалы проект бәясенең 10% тан 15% ка кадәр | 3 |
| | инициативалы проект бәясенең 5% тан 10% ка кадәр | 2 |
| | инициативалы проект бәясенең 5% ына кадәр | 1 |
| 2.4.3. | Халык тарафыннан инициативалы проектка ярдәм итү дәрәҗәсе | |
| | җирлек территориясендә инициатив проект гамәлгә ашырыла торган халык санынннан 15% на кадәр | 5 |
| | җирлек территориясендә инициативалы проект гамәлгә ашырыла торган халык санынннан 10% - тан 15% - ка кадәр | |
| | җирлек территориясендә инициатив проект гамәлгә ашырыла торган халык санынннан 5% - нан 10% - ка кадәр | |
| | җирлек территориясендә инициативалы проект гамәлгә ашырыла торган халык санынннан 1% - тан 5% - ка кадәр | |
| | җирлек территориясендә инициативалы проект гамәлгә ашырыла торган халык санынннан 1% ка кадәр | |
| «Рейтинг критерийлар» нәтиҗәсе | «Конкурс сайлап алуын узу критерийлары» төркеменә керүче инициативалы проектка һәр критерий буенча бирелгән баллар суммасы | |
| Инициативалы проектны бәяләү | «Конкурс сайлап алуын узу критерийлары» нәтиҗәсе, «Рейтинг критерийлар» нәтиҗәсе | |